РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » 04 2021 г. №265

2021 елга "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы Карары белән расланган №696 «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына 3 нче кушымтада китерелгән, авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә кушымтаның 15 пункты нигезендә, һәм “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең авыл территорияләрен комплекслы үстерү һәм кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында карары нигезендә һәм «Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау һәм авыл территорияләрендә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклыклар бирү Тәртибенең 19 пунктына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 18 ноябрендәге 696 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында " 2020 ел, 14 май, 387 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен Татарстан Республикасында авыл территорияләрендәге торакның бер квадрат метр гомуми мәйданы кыйммәтен раслау турында» 2021 ел, 24 март, 162 нче карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма

комитетының 2020 ел, 14 август, №599 "2020-2025 елларга Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы авыл территорияләрен комплекслы үстерү" муниципаль программасын раслау турында" карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районы буенча 2021 елга авыл территорияләрендәге торак урынының бер квадрат метр гомуми торак мәйданы бәясе күрсәткечен 29 000 сум күләмендә расларга, ул социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен кулланылырга тиеш.

2. Әлеге карарны өч эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина